КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 декабрь г.Казань № 1199

Казан шәһәре, Несмелов урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

Советлар Союзы Герое Девятаев Михаил Петрович истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм «Александр Печерский истәлеге фонды» коммерциягә карамаган оешмасының М.П.Девятаевка Казан шәһәре, Несмелов урамы, 7 нче йорт адресы буенча бина фасадына татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Дошман очкычында
фашист концлагереннан
легендар рәвештә качкан
Советлар Союзы Герое
Михаил Петрович Девятаев
1934 – 1937 елларда
Казан елга техникумында
укыды

В 1934 – 1937 гг.
в Казанском речном техникуме
учился Герой Советского Союза
Михаил Петрович Девятаев,
совершивший легендарный побег
из фашистского концлагеря
на вражеском самолете».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин